**ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ**
**ТУКАЙ МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ**
**«ШИЛНӘБАШ АВЫЛ ҖИРЛЕГЕ»**
**БАШКАРМА КОМИТЕТЫ**

# КАРАР

«16» февраля 2024 ел Шилнәбаш авылы № 4

2024 елга Тукай муниципаль районы Шилнәбаш авыл җирлеге территориясендә төзекләндерү өлкәсендә муниципаль контрольне гамәлгә ашырганда закон белән саклана торган кыйммәтләргә зарар (зыян) китерү куркынычларын профилактикалау программасын раслау турында

«Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» 2003 елның 6 октябрендәге 131-ФЗ номерлы Федераль законга, «Россия Федерациясендә дәүләт контроле (күзәтчелеге) һәм муниципаль контроль турында» 2020 елның 31 июлендәге 248-ФЗ номерлы Федераль законга, «Контроль (күзәтчелек) органнары тарафыннан закон белән саклана торган кыйммәтләргә зарар (зыян) китерү куркынычын профилактикалау программасын эшләү һәм раслау кагыйдәләрен раслау турында» 2021 елның 25 июнендәге 990 номерлы Россия Федерациясе Хөкүмәте карарына, Татарстан Республикасы Тукай муниципаль районы Шилнәбаш авыл җирлеге уставына таянып, Тукай муниципаль районы Шилнәбаш авыл җирлеге Башкарма комитеты

**КАРАР БИРӘ:**

1. 2024 елга Тукай муниципаль районы Шилнәбаш авыл җирлеге территориясендә төзеклəндерү өлкәсендә муниципаль контрольне гамәлгә ашырганда закон белән саклана торган кыйммәтләргә зарар (зыян) китерү куркынычларын профилактикалау программасын (бирелә) расларга
2. Әлеге карарны авыл җирлегенең мәгълүмат стендларында игълан итәргә.
3. Әлеге карарны Тукай муниципаль районының рәсми сайтында «авыл җирлекләре» бүлегендә (tukay.tatarstan.ru) һәм Татарстан Республикасы рәсми хокукый мәгълүмат порталында (pravo.tatarstan.ru) урнаштырырга.
4. Әлеге карар игълан ителгән көннән үз көченә керә.
5. Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тотуны Татарстан Республикасы Тукай муниципаль районы Шилнәбаш авыл җирлеге Башкарма комитеты җитәкчесенә йөкләргә.

Башкарма комитет җитәкчесе О.А. Чекушкова

Исполнительный комитет ШИЛЬНЕБАШСКОГО сельского поселения ОГРН 1081682004977 ИНН 1639032400

Татарстан Республикасы Тукай муниципаль районы Шилнәбаш авыл җирлеге Башкарма комитетының 2024 елның 16 февраля 4 номерлы карарына кушымта

**2024 елга Тукай муниципаль районы Шилнәбаш авыл җирлеге территориясендә төзекләндерү өлкәсендә муниципаль контрольне гамәлгә ашырганда закон белән саклана торган кыйммәтләргә зарар (зыян) китерү куркынычларын профилактикалау программасы**

1. Төзекләндерү өлкәсендә муниципаль контрольне гамәлгә ашыруның агымдагы торышын анализлау, контроль (күзәтчелек) органның профилактика эшчәнлегенең агымдагы үсеш дәрәҗәсен тасвирлау, профилактика программасы хәл итүгә юнәлдерелгән проблемаларны характеристикалау.

Әлеге программа «Россия Федерациясендә дәүләт контроле (күзәтчелеге) һәм муниципаль контроль турында» 2020 елның 31 июлендәге 248-ФЗ номерлы Федераль законның 44 статьясы, «Контроль (күзәтчелек) органнары тарафыннан закон белән саклана торган кыйммәтләргә зарар (зыян) китерү куркынычын профилактикалау программасын эшләү һәм раслау кагыйдәләрен раслау турында» 2021 елның 25 июнендәге 990 номерлы Россия Федерациясе Хөкүмәте карары нигезендә эшләнгән һәм төзекләндерү өлкәсендә муниципаль контрольне гамәлгә ашырганда закон белән саклана торган кыйммәтләргә зарар (зыян) китерү куркынычларын профилактикалау буенча чаралар комплексын күздә тота.

«Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» 2003 елның 6 октябрендәге 131-ФЗ номерлы Федераль закон, Татарстан Республикасы Тукай муниципаль районы Шилнәбаш авыл җирлеге уставы нигезендә Татарстан Республикасы Тукай муниципаль районы Шилнәбаш авыл җирлеге территориясендә төзекләндерү өлкәсендә муниципаль контрольне гамәлгә ашыру буенча вәкаләтле орган (алга таба - контроль органы) булып Татарстан Республикасы Тукай муниципаль районы Шилнәбаш авыл җирлеге тора. Татарстан Республикасы Тукай муниципаль районы Шилнәбаш авыл җирлегенең төзекләндерү өлкәсендә муниципаль контрольне гамәлгә ашыруга вәкаләтле структур бүлекчәсе булып Шилнәбаш авыл җирлеге Башкарма комитеты (алга таба – контроль органы) тора.

Төзекләндерү өлкәсендә муниципаль контроль предметы булып тора:

«Татарстан Республикасы Тукай муниципаль районы Шилнәбаш авыл җирлеген төзекләндерү кагыйдәләрен раслау турында» Татарстан Республикасы Тукай муниципаль районы Шилнәбаш авыл җирлеге Советының 2012 елның 15 октябрендәге 15/1 номерлы карары белән расланган Татарстан Республикасы Тукай муниципаль районы Шилнәбаш авыл җирлеге территориясен төзекләндерү кагыйдәләре (алга таба – Кагыйдәләр) белән билгеләнгән мәҗбүри таләпләрне, инвалидларның социаль, инженерлык һәм транспорт инфраструктуралары һәм күрсәтелә торган хезмәтләрдән файдалана алуын тәэмин итү таләпләрен юридик затлар, шәхси эшмәкәрләр, гражданнар (алга таба – контрольдәге затлар) тарафыннан үтәү.

Төзекләндерү өлкәсендә муниципаль контроль объектлары (алга таба – контроль объектлары) булып тора:

- Татарстан Республикасы Тукай муниципаль районы Шилнәбаш авыл җирлеге территориясендә төзекләндерү өлкәсендә контрольдәге затларның эшчәнлеге, гамәлләре (гамәл кылмавы), алар кысаларында мәҗбүри таләпләр, шул исәптән эшчәнлек, гамәлләр кылучы (гамәл кылмаучы) контрольдәге затларга карата куелган таләпләр үтәлергә тиеш;

- контрольдәге затларның эшчәнлек нәтиҗәләре, шул исәптән мәҗбүри таләпләр куелган эшләр һәм хезмәтләр;

- контрольдәге затлар биләгән һәм (яки) файдаланган һәм аларга төзекләндерү өлкәсендә мәҗбүри таләпләр куелган биналар, корылмалар, төзелмәләр, территорияләр, җир кишәрлекләрен дә кертеп, һ.б. объектлар

Татарстан Республикасы Тукай муниципаль районы Шилнәбаш авыл җирлеге территориясендә профилактик эшчәнлекне үстерү һәм гамәлгә ашыру кысаларында 2023 елда түбәндәге эшчәнлек башкарылган:

- гомуми файдаланудагы мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендә (интернет челтәрендә) контроль эшчәнлеккә багышланган махсус бүлектә (махсус бүлеккә керү район рәсми сайтының баш (төп) битеннән башкарылырга тиеш), районның рәсми сайтында махсус бүлектә урнаштыру зарурлыгы «Дәүләт контроле турында» 2020 елның 31 июлендәге 248-ФЗ номерлы Федераль законның 46 статьясы 3 өлешендә билгеләнгән мәгълүматлар;

- Тукай муниципаль районының рәсми сайтында (tukay.tatarstan.ru) «авыл җирлекләре» бүлегендә мәҗбүри таләпләрне үтәү мәсьәләләре буенча, шулай ук Росреестр, Россельхознадзор, РФ Икътисади үсеш министрлыгы, Татарстан Республикасы Дәүләт төзелеш күзәтчелеге инспекциясе, Татарстан Республикасы сәнәгать һәм сәүдә министрлыгы тарафыннан бирелә торган мәҗбүри таләпләрне үтәү мәсьәләләре буенча, эшмәкәрләр берләшмәсенә дәүләт ярдәме чаралары турында, шулай ук 2023 елда дәүләт контролен (күзәтчелеген) һәм муниципаль контрольне гамәлгә ашыру үзенчәлекләре турында мәгълүмати материаллар – әзер контент (пресс – релизлар, белешмәләр, видеороликлар һ.б.) даими урнаштырыла;

- мәҗбүри таләпләрне, муниципаль хокукый актларда билгеләнгән таләпләрне үтәү мәсьәләләре буенча консультацияләр бирелде.

2. Профилактика программасын гамәлгә ашыруның максатлары һәм бурычлары

Профилактика программасының төп максатлары булып тора:

1. Барлык контрольдәге затларның мәҗбүри таләпләрне намуслы үтәвен стимуллаштыру;

2. Мәҗбүри таләпләрне бозуга һәм (яки) закон белән саклана торган кыйммәтләргә зарар (зыян) китерүгә этәрүче шартларны, сәбәпләрне һәм факторларны бетерү;

3. Мәҗбүри таләпләрне контрольдәге затларга җиткерү өчен шартлар тудыру, аларны үтәү ысуллары турында мәгълүматлылыкны арттыру.

Профилактика программасының профилактика чараларын үткәрү түбәндәге бурычларны хәл итүгә юнәлдерелгән:

1) Закон белән саклана торган кыйммәтләргә зарар (зыян) китерү куркынычларын бозуны профилактикалау системасын ныгыту.

2) Юридик затлар җитәкчеләренең, шәхси эшмәкәрләр һәм гражданнарның мәгълүматлылыгын, хокуки аңын һәм хокукый культурасын арттыру.

3) Гражданнарның гомеренә, сәламәтлегенә зарар китерү куркынычы факторларын, мәҗбүри таләпләрне бозуга китерә торган сәбәпләрне һәм шартларны ачыклау, янауны бетерү яки киметү ысулларын билгеләү.

4) Төзекләндерү өлкәсендә муниципаль контроль гамәлгә ашырылган субъектлар тарафыннан мәҗбүри таләпләрне бозуга китерүче сәбәпләрне, факторларны һәм шартларны бетерү буенча чаралар күрү.

3. Профилактика чаралары исемлеге, аларны үткәрү срогы (дәвамлылыгы)

| № | Чараның исеме | Башкару срогы | Гамәлгә ашыру өчен җаваплы структур бүлекчә |
|---|---|---|---|
| 1. | Мәҗбүри таләпләрне үтәү мәсьәләләре буенча мәгълүмат бирү | даими | Шилнәбаш авыл җирлеге Башкарма комитеты |
| 2. | Кисәтүләр бирү | 248-ФЗ номерлы Федераль законның 49 статьясында каралган нигезләр булганда | Шилнәбаш авыл җирлеге Башкарма комитеты |
| 3. | Консультацияләр | контрольдәге затлар һәм аларның вәкилләре мөрәҗәгатьләре буенча | Шилнәбаш авыл җирлеге Башкарма комитеты |

3.1 Контроль орган «интернет» мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендә Тукай муниципаль районының рәсми сайтында (җирлек бүлеге) контроль эшчәнлеккә багышланган махсус бүлектә (махсус бүлеккә керү район рәсми сайтының баш (төп) битеннән башкарылырга тиеш), массакүләм мәгълүмат чараларында, дәүләт мәгълүмат системаларында контрольдәге затларның шәхси кабинетлары (алар булганда) юлы белән һәм башка формаларда тиешле мәгълүматны урнаштыру аша контрольдәге һәм башка кызыксынган затларга мәҗбүри таләпләрне үтәү мәсьәләләре буенча мәгълүмат бирүне гамәлгә ашыра.

Контроль орган Тукай муниципаль районының рәсми сайтында (tukay.tatarstan.ru) «авыл җирлекләре» бүлегендә һәм Татарстан Республикасы рәсми хокукый мәгълүмат порталында (pravo.tatarstan.ru) 248-ФЗ номерлы Федераль законның 46 статьясы 3 өлеше белән билгеләнгән мәгълүматларны урнаштырырга һәм актуаль хәлдә тотарга тиеш.

3.2 Контроль орган мәҗбүри таләпләрне бозу әзерләнү турында мәгълүмат булганда яки мәҗбүри таләпләрне бозу билгеләре булганда һәм (яки) мәҗбүри таләпләрне бозу закон белән саклана торган кыйммәтләргә зыян китергән яки закон белән саклана торган кыйммәтләргә зыян китерү куркынычы тудырган дигән расланган мәгълүматлар булмаса, контрольдәге затка мәҗбүри таләпләрне бозуга юл куймау турында кисәтү (алга таба – кисәтү) игълан итә һәм мәҗбүри таләпләрне үтәүне тәэмин итү буенча чаралар күрергә тәкъдим итә.

Кисәтү Россия Икътисади үсеш министрлыгының «Контроль (күзәтчелек) органы тарафыннан кулланыла торган документларның типлаштырылган формалары турында» 2021 елның 31 мартындагы 151 номерлы боерыгы белән расланган форма буенча төзелә.

Контрольдәге зат кисәтү алганнан соң ун эш көне эчендә Контроль органга кисәтүгә карата каршылык бирергә хокуклы.

Контроль орган кисәтүгә каршылыкны аны алганнан соң унбиш эш көне эчендә карый һәм түбәндәге карарларның берсен кабул итә:

1) кисәтүне гамәлдән чыгару формасында каршылыкны канәгатьләндерә;

2) баш тарту сәбәбен күрсәтеп, каршылыкны канәгатьләндерүдән баш тарта.

Контроль орган контрольдәге затка кисәтүгә карата каршылык каралган көннән алып биш эш көненнән дә соңга калмыйча каршылыкны карау нәтиҗәләре турында хәбәр итә.

Контроль орган мәҗбүри таләпләрне бозуга юл куймау турында бирелгән кисәтүләрнең исәбен алып бара һәм тиешле мәгълүматны башка профилактик чаралар һәм контроль чаралар үткәрү өчен куллана.

3.3 Контрольдге затларга һәм аларның вәкилләренә консультация бирү муниципаль контрольне оештыру һәм гамәлгә ашыру белән бәйле мәсьәләләр буенча башкарыла:

1) контроль чаралар үткәрү тәртибе;

2) контроль чараларны үткәрү дәвамлылыгы;

3) контроль чаралар нәтиҗәләре буенча карарлар кабул итү тәртибе;

4) Контроль орган карарларына шикаять бирү тәртибе.

Муниципаль контроль секторы хезмәткәрләре контрольдәге затларга һәм аларның вәкилләренә консультацияләр бирәләр:

1) телефон аша, видео-конференц элемтәсе аша, шәхси кабул итүдә яки профилактик чара, контроль чара үткәрү барышында телдән аңлатмалар рәвешендә;

2) контрольдәге затларның һәм аларның вәкилләренең бертөрле мөрәҗәгатьләре буенча рәсми сайтта контроль органның вәкаләтле вазифаи заты тарафыннан имзаланган язма аңлатма урнаштыру юлы белән.

Шәхси кабул итүдә һәр мөрәҗәгать итүчегә инспекторлар тарафыннан шәхси консультация 10 минуттан артмаска тиеш.

Контроль орган контрольдәге затларга һәм аларның вәкилләренә телдән консультация бирү мәсьәләләре буенча язма рәвештә мәгълүмат бирми.

Контрольдәге затларга һәм аларның вәкилләренә язмача консультация бирү Контроль орган карарларына шикаять бирү тәртибе мәсьәләләре буенча башкарыла.

Контрольдәге зат «Россия Федерациясе гражданнары мөрәҗәгатьләрен карау тәртибе турында» 2006 елның 2 маендагы 59-ФЗ номерлы Федераль закон белән билгеләгән срокларда язма җавап бирү турында запрос җибәрергә хокуклы.

Контроль орган үткәрелгән консультацияләрнең исәбен алып бара.

Профилактика программасының нәтиҗәлелек һәм эффективлык күрсәткечләре

| № | Күрсәткечнең исеме | Максатчан зурлыклар |
|---|---|---|

| | | |
|---|---|---|
| 1. | «Россия Федерациясендә дәүләт контроле (күзәтчелеге) һәм муниципаль контроль турында» 2021 елның 31 июлендәге 248-ФЗ номерлы Федераль законның 46 статьясы 3 өлешенигезендә «интернет» челтәрендә контроль органның рәсми сайтында урнаштырылган мәгълүматның тулылыгы | 100% |
| 2. | Контрольдәге затларның һәм аларның вәкилләренең Контроль (күзәтчелек) органы консультациясеннән канәгатьлеге | Мөрәҗәгать итүчеләр санынннан 90% |

Башкарма комитет җитәкчесе О.А. Чекушкова

Исполнительный комитет ШИЛЬНЕБАШСКОГО сельского поселения ОГРН 1061682004977 ИНН 1639032400